ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е К А Р А Р

2019 елның «01» октябре №1387

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 8 февралендәге 45 номерлы «Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары белән расланган Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру, җайга салу карарларын әзерләү һәм кабул итү өлешендә муниципаль идарә процессларының нәтиҗәлелеген күтәрү һәм камилләштерү максатларында, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 8 февралендәге 45 номерлы «Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары белән расланган Муниципаль норматив

хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 бүлекнең 1.6 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын раслау, җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын раслау, төзелешкә рөхсәт бирү, җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә файдалануга тапшыру өчен рөхсәт бирү, җирлекләрнең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау, җирләрне резервлау һәм алардан алу, шул исәптән сатып алу юлы белән, җирлек чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләре;»;

2.Әлеге карарны рәсми публикатор- «Лениногорские вести» газетында бастырырга, Лениногорск муниципаль районы рәсми порталында http://leninogorsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары З.Г. Михайловага йөкләргә.

Җитәкче Н.Р. Залаков

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72